Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Олыяз авыл җирлеге башлыгы

КАРАРЫ

2021 елның 10 ноябре, № 4

**«Кукмара муниципаль районы Олыяз авыл җирлегенең Балыклы авылы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Кукмара муниципаль районы Олыяз авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1.2021 елның 26 ноябрендә 10 сәгать 00 минутта Кукмара муниципаль районы Олыяз авыл җирлеге Балыклы авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенын билгеләргә. Балыклы авылы, Үзәк урам, 23 нче йорт адресы буенча урнашкан авыл клубы бинасында гражданнар җыены үткәрергә.

2.2021 елның 26ноябрендә 19 сәгать 00 минутта Кукмара муниципаль районы Олыяз авыл җирлеге Балыклы авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенын билгеләргә. Балыклы авылы, Үзәк урам, 23 нче йорт адресы буенча урнашкан авыл клубы бинасында гражданнар җыены үткәрергә.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, гомуми белем бирү мәктәпләрендә укучылар, I төркем инвалидлары , 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге пенсионерлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Олыяз авыл җирлегенең Олыяз авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән, 2022 елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Балыклы авылының яр буе зонасын төзекләндерү һәм карап тоту (кыргый куакларны, агачларны кисү, чүп-чар чыгару, ягулык-майлау материаллары, бульдозер, экскаватор эше, комны тигезләү) смета документациясен төзү;

- Балыклы авылында энергия саклаучы лампалар, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу;

- Балыклы авылы мәдәният йорты бинасына тышкы видеокүзәтү камералары сатып алу һәм урнаштыру?

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Гражданнар җыенын оештыручы итеп, Олыяз авылы Башкарма комитетын билгеләргә.

4. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Олыяз авыл җирлеге башлыгы: Р.Ф.Маликов